1.1. «Татарстан Республикасы тарихи һәм мәдәни истәлекләрен торгызу Республика фонды» коммерциячел булмаган оешмасы (алга таба – Фонд) унитар, коммерциячел булмаган, әгъзалыгы булмаган, табыш алуны үз эшчәнлегенең төп максаты итеп куймаучы һәм алынган табышны аны гамәлгә куючыга тапшырмаучы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы тарихи һәм мәдәни истәлекләрен торгызу Республика фондын төзү турында» 2010 елның 17 февралендәге ПУ-71 номерлы Указы нигезендә фонд рәвешендә төзелгән оешма булып тора. Фонд эшчәнлегеннән табыш алынганда, табыш Фондның уставында каралган максатларда тотыла.

1.2. Фондны гамәлгә куючы – Татарстан Республикасы Рәисе йөзендә Татарстан Республикасы (алга таба – Гамәлгә куючы).

1.3. Фондка аны Гамәлгә куючы тарафыннан тапшырылган мөлкәт Фондның милке булып тора. Гамәлгә куючы Фондка карата мөлкәти хокукларга ия булмый һәм аның йөкләмәләре буенча җавап тотмый, ә Фонд үзен Гамәлгә куючы йөкләмәләре буенча җавап тотмый.

1.4. Фонд үз мөлкәтен әлеге Устав нигезендә билгеләнгән максатларда файдалана.

1.5. Үз эшчәнлегендә Фонд Россия Федерациясе Конституциясенә, Россия Федерациясе Граждан кодексына, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Рәисе указларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, әлеге Уставка таяна.

1.6. Юридик зат буларак законнарда каралган тәртиптә дәүләт теркәве узганнан соң, Фонд төзелгән булып санала, милкендә аерым мөлкәте була, үз йөкләмәләре буенча шушы мөлкәте белән җавап бирә, үз исеменнән мөлкәти һәм мөлкәти булмаган хокуклар алырга һәм гамәлгә ашырырга, йөкләмәләрен үтәргә, судка бирүче һәм җавап тотучы булырга хокуклы.

1.7. Фонд эшчәнлеге срогын чикләмичә төзелә.

1.8. Фондның үз балансы, Фондның рус һәм татар телләрендә тулы атамасы язылган түгәрәк мөһере, үз атамасы язылган штамплары һәм бланклары, шулай ук эмблемасы бар.

Эмблема очлаеп торган арка рәвешендә булып, аның эчендә очлаеп торган, тәңгәл симметрик ике арка ясалган, шуларның сулдагысының эчке сызыгы – өчпочмак, ә уңдагысыныкы ярым әйләнә рәвешендә. Кече аркалар аралыгында лалә чәчәген сак кына тоткан ике кул контуры урнаштырылган. Чәчәк ачык китап аша уза. Кече аркалар астында стильләштерелгән көнчыгыш һәм борынгы рус хәрефләре белән ике телдә – рус һәм татар телләрендә «Яңарыш» сүзе (Фондның атамасы) язылган.

1.9. Фонд билгеләнгән тәртиптә банкларда исәп-хисап, валюта һәм башка счетлар ача.

1.10. Фонд Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бухгалтерлык исәбе һәм статистика хисабы алып бара.

1.11. Фонд үзенең максатларын гамәлгә ашыру өчен хезмәт шартнамәсе шартларында физик затларны эшкә алырга хокуклы.

1.12. Фонд документларның (идарә, финанс-хуҗалык, кадрларга кагылышлы һәм башкаларның) саклануы өчен җаваплы була.

1.13. Фондның тулы атамасы: «Татарстан Республикасы тарихи һәм мәдәни истәлекләрен торгызу Республика фонды» коммерциячел булмаган оешмасы.

Фондның кыскартылган атамасы: «Яңарыш» Республика Фонды.

1.14. Фонд урнашкан урын: 420014, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Батурин урамы, 7 А йорт.

1.15. Россия Федерациясе граждан законнары һәм әлеге Устав нигезендә Фонд филиалларын төзергә һәм вәкиллекләрен ачарга хокуклы.

1.16. Фондның Административ Советы тарафыннан расланган нигезләмәләре буенча Фонд филиаллары һәм вәкиллекләре Фонд исеменнән эш алып бара. Фонд филиаллары һәм вәкиллекләре, алар төзелгән (ачылган) очракта, әлеге Уставта күрсәтелә.

## II. Фонд эшчәнлегенең предметы, төп максатлары һәм рәвешләре

2.1. Фондның эшчәнлеге предметы булып түбәндәгеләргә ярдәм итү тора:

борынгы Болгар шәһәре, Свияжск утрау-шәһәрчеге территориясендә урнашкан тарихи һәм мәдәни мирас истәлекләрен, Татарстан Республикасындагы башка тарихи һәм мәдәни истәлекләрне торгызу һәм яңадан төзүгә;

«Болгар ислам академиясе» фәнни-белем бирү һәм дини-мәгърифәти мөселман үзәген һәм полилингваль мәгариф комплексларын төзүгә һәм үстерүгә, Казан Богородицкий монастыре комплексы кысаларында Казан Мәрьям Ана иконасы Соборын яңадан төзүгә;

Татарстан Республикасының күпмилләтле халкының тарихи, мәдәни һәм рухи традицияләрен, татарларның һәм Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче башка халыкларның милли-мәдәни үзенчәлеген һәм традицияләрен саклап калу һәм үстерүгә.

2.2. Фонд эшчәнлегенең төп максатлары түбәндәгеләр:

борынгы Болгар шәһәре, Свияжск утрау-шәһәрчеге территориясендә урнашкан тарихи һәм мәдәни мирас истәлекләрен, тарих, археология, архитектура, шәһәр төзелеше, сәнгать, эстетика, этнология яисә антропология, социаль мәдәният күзлегеннән чыгып караганда, кыйммәтле дип табылган башка объектларны саклауга, яңадан төзүгә, реставрацияләүгә ярдәм күрсәтү, шулай ук моның өчен кирәкле финанс ресурсларын җәлеп итү;

«Болгар ислам академиясе» фәнни-белем бирү һәм дини-мәгърифәти мөселман үзәген һәм полилингваль мәгариф комплексларын төзү һәм үстерү, Казан Богородицкий монастыре комплексы кысаларында Казан Мәрьям Ана иконасы Соборын яңадан төзү, шулай ук моның өчен кирәкле финанс ресурсларын җәлеп итү;

Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын популярлаштыру;

матди булмаган мәдәни мирасны саклау һәм популярлаштыру;

җәмгыятьнең культура дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлтелгән эшчәнлеккә ярдәм итү;

ЮНЕСКО белән Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан тарихи, мәдәни һәм рухи истәлекләрен саклау мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек итү;

Татарстан Республикасының фәнни, мәдәни, интеллектуаль һәм туристлык потенциалын булдыруга ярдәм итү.

2.3. Фонд үз максатларына ирешү өчен түбәндәге эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыра:

«Болгар ислам академиясе» фәнни-белем бирү һәм дини-мәгърифәти мөселман үзәген һәм полилингваль мәгариф комплексларын төзү һәм үстерү, Казан Богородицкий монастыре комплексы кысаларында Казан Мәрьям Ана иконасы Соборын яңадан төзү белән бәйле борынгы Болгар шәһәре, Свияжск утрау-шәһәрчеге территориясендә урнашкан тарихи һәм мәдәни мирас истәлекләрен, тарих, археология, архитектура, шәһәр төзелеше, сәнгать, эстетика, этнология яисә антропология, социаль мәдәният күзлегеннән чыгып караганда, кыйммәтле дип табылган башка объектларны саклау, яңадан төзү, реставрацияләү белән бәйле чараларны финанслау;

билгеләнгән таләпләр нигезендә тарихи, дини, мәдәни яисә табигатьне саклау ягыннан әһәмиятле булган биналарны, объектларны һәм территорияләрне һәм борынгы зиратларны саклау һәм тиешенчә карап тотуны тәэмин итү;

тарихи һәм дини әһәмияткә ия территорияләр белән бәйле объектлар, туристлык индустриясен үстерү өчен уңай шартлар тәэмин итүче объектлар төзүгә ярдәм итү, шундый төзелешләрне финанслау;

борынгы Болгар шәһәре, Свияжск утрау-шәһәрчеге территориясендә урнашкан тарихи һәм мәдәни мирас истәлекләрен, Татарстан Республикасында башка мәдәни һәм тарихи һәйкәлләрне саклап калу, яңадан төзү, реставрацияләү эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләрен гамәлгә ашыру, Татарстан Республикасы территориясендә тарихи һәм рухи әһәмияттәге объектларны төзү, «Болгар ислам академиясе» фәнни-белем бирү һәм дини-мәгърифәти мөселман үзәген һәм полилингваль мәгариф комплексларын төзү һәм үстерү, Казан Богородицкий монастыре комплексы кысаларында Казан Мәрьям Ана иконасы Соборын яңадан төзү өчен илебез һәм чит ил инвестицияләрен, кредитларын, шул исәптән конкурслар, аукционнар, күргәзмәләр һәм лотореяләр уздыру юлы белән дә, җәлеп итү;

фәнни тикшеренүләр, фәнни-гамәли конференцияләр, симпозиумнар, киңәшмәләр, конкурслар, күргәзмәләр һәм семинарлар, шул исәптән халыкара дәрәҗәдәгеләрен дә, тарихи-мәдәни тикшеренүләр уздыруга ярдәм итү;

мәгариф, белем бирү, фән, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә чаралар уздыруга ярдәм итү;

мәдәни мирас объектларын дәүләт саклавы, аларны саклап калу, файдалану һәм популярлаштыру өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыручы һәм мөнәсәбәтләрне җайга салучы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте Башкарма органына законнарда каралган тәртиптә тиешле эшчәнлекне алып баруда ярдәм күрсәтү;

Татарстан Республикасында гамәлгә ашырылучы тарихи һәм мәдәни истәлекләрне торгызуга юнәлтелгән программаларда билгеләнгән тәртиптә катнашу;

алынган керемнәрне әлеге Уставта билгеләнгән максатларга ирешүгә тоту өчен законнар нигезендә хуҗалык операцияләре (алыш-бирешләр) башкару.

2.4. Үз эшчәнлеген тормышка ашыру өчен Фонд, кирәк булганда, законнарда билгеләнгән тәртиптә лицензияләр, рөхсәт кәгазьләре, шулай ук башка рөхсәт документлары ала.

## III. Фондның хокуклары

3.1. Фонд түбәндәгеләргә хокуклы:

Фонд максатларына туры килә торган һәм ул үзе шуларны күздә тотып булдырылган, җәмгыять өчен файдалы максатларга ирешү өчен эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;

Россия Федерациясе Хөкүмәте, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән һәм мондый программаларда каралган тәртиптә һәм шартларда тарихи һәм мәдәни истәлекләрне саклауга, яңадан торгызуга юнәлтелгән программаларны гамәлгә ашыруда катнашырга;

кыйммәтле кәгазьләр, мөлкәти һәм мөлкәти булмаган хокуклар алырга һәм гамәлгә ашырырга, шулай ук федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында каралаган очракларда, күрсәтелгән норматив актларда тәэмин итү билгеләнгән булганда, облигацияләр һәм башка кыйммәтле эмиссия кәгазьләре чыгарырга;

законнарда билгеләнгән тәртиптә юридик затлар булдырырга һәм (яисә) аларда катнашырга;

күчемле һәм (яки) күчемсез милек алырга, аңа ия булырга, аның белән идарә итәргә, арендага, наемга тапшырырга, алырга, законнарда каралган теләсә нинди башка рәвештә аның белән эш йөртергә;

җир кишәрлекләрен, шул исәптән алырны сатып алу яисә арендалау юлы белән дә алырга, шулай ук аның милкендәге җир кишәрлекләрен юридик һәм физик затларга арендага тапшырырга;

үз вәкаләтләре чикләрендә поручительлек бирергә;

әлеге Уставта билгеләнгән максатларга ирешү, шулай ук Фонд эшчәнлеген тәэмин итү өчен милек сатудан алынган керемне тотарга;

Фонд милке белән идарә итү өчен кирәкле акча кертергә һәм операцияләр уздырырга;

әлеге Уставта каралаган максатларда кредит ресурслары җәлеп итәргә һәм аларны тотарга;

үз эшчәнлеге мәсьәләләре буенча дәүләт хакимияте, җирле үзидарә органнары, милекнең барлык төрләрендәге оешмалар белән, шул исәптән килешүләр төзү юлы белән дә, хезмәттәшлек итәргә;

Россия Федерациясе законнарында каралаган тәртиптә күргәзмә, нәшрият эшчәнлеге алып барырга, шул исәптән басмалар, кино-, теле-, видео- һәм аудиопродукция чыгаруны башкарырга;

Россия Федерациясенең коммерциячел булмаган оешмалар турындагы законнарында каралаган вәкаләтләрне тулы күләмдә башкарырга;

Фонд эшчәнлеге предметы кысаларында турыдан-туры халыкара контактлар һәм элемтәләр тотарга;

Фондның әлеге Уставта каралган эшчәнлеге максатларына туры килә торган, законнарда тыелмаган эшчәнлек алып барырга.

3.2. Фонд әлеге Уставта каралган эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле консультатив комитетлар, эш төркемнәре һәм башка эш органнары төзергә, шулай ук мондый эш органнары әгъзаларына аларның эше белән бәйле чыгымнарны түләргә хокуклы.

## IV. Фондның милке һәм аны формалаштыру чыганаклары

4.1. Фонд үз милкендә биналар, корылмалар, торак фонды, җиһазлар, инвентарь, сумнарда һәм чит ил валютасында акча, кыйммәтле кәгазьләр һәм башка төрле мөлкәт тота ала. Фонд үз милкендә яисә башка хокук белән җир кишәрлекләре тота ала.

4.2. Фонд үз йөкләмәләре буенча, Россия Федерациясе законнарында каралганча, аңа түләү салынырга мөмкин булган мөлкәте белән җавап бирә.

4.3. Фонд тарафыннан үз эшчәнлеге барышында булдырылган, сатып алынган яисә физик һәм юридик затларга тапшырылган мөлкәт, акча, акцияләр, башка кыйммәтле кәгазьләр, интеллектуаль милеккә хокукларны да кертеп, шулай ук Гамәлгә куючы тапшырган мөлкәт аның милке булып тора.

4.4. Акчалата һәм башка рәвешләрдә Фонд милкен булдыру чыганагы булып түбәндәгеләр тора:

Гамәлгә куючы тарафыннан законнар нигезендә тапшырылган мөлкәт, шулай ук гамәлгә куючыдан башка кертемнәр;

ирекле милек взнослары һәм хәйрия ителгән милек;

товар сату, эшләр, хезмәт күрсәтүләр башкарудан керем;

акцияләр, облигацияләр, башка кыйммәтле кәгазьләр һәм акча кертемнәреннән алына торган дивидендлар (керемнәр, процентлар);

Фонд милкеннән алына торган керемнәр;

эшкуарлык эшчәнлегеннән керемнәр;

гамәлдәге законнарда тыелмаган башка керемнәр.

## V. Исәп, хисап һәм аудит

5.1. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Фонд бухгалтерлык исәбе һәм статистика хисабы алып бара.

5.2. Фонд Россия Федерациясе законнары һәм әлеге Устав нигезендә Гамәлгә куючы, Фондның Попечительлек Советы һәм Фондның Административ Советы алдында квартал саен, билгеләнгән вакытларда дәүләт статистика органнары һәм салым органнары, башка органнар алдында хисап бирә.

5.3. Фондның Гамәлгә куючыга, Попечительлек Советына һәм Фондның Административ Советына Фонд һәр елның 31 мартыннан да соңга калмыйча үзенең узган финанс елында эшчәнлеге турында хисап бирә.

Фондның финанс елы календарь ел белән тәңгәл килә.

5.4. Фонд үз мөлкәтеннән файдалануы турында законнар нигезендә ел саен хисабын бастырып чыгара.

5.5. Фондның эшчәнлегенә ел саен аудиторлык тикшерүе уздырылырга тиеш.

5.6. Аудиторлык функцияләрен башкаруны гамәлгә ашыручы оешмалар гамәлдәге законнарда каралган һәм бу эшчәнлек рәвешенә бәйле барлык таләпләргә туры килергә тиеш.

## VI. Фондны Гамәлгә куючы

6.1. Гамәлгә куючы вәкаләтләренә түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү керә:

Фондның Уставын раслау һәм аңа үзгәрешләр кертү;

Фонд эшчәнлегенең еллык хисапларын карау;

Фондның Попечительлек Советы персональ составын, аның Рәисен һәм Рәисе урынбасарларын раслау;

Фондның Административ Советы персональ составын һәм аның Җитәкчесен раслау;

Фондның Попечительлек Советының, аның Рәисенең һәм Рәисе урынбасарларының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында карар кабул итү;

Фондның Административ Советының һәм аның Җитәкчесенең вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында карар кабул итү;

6.2. Гамәлгә куючы шулай ук законнар нигезендә башка функцияләр һәм вәкаләтләр башкара.

## VII. Фонд органнары

7.1. Фонд органнары түбәндәгеләр:

Фондның Попечительләр Советы – Фонд эшчәнлегенә күзәтчелек итүче орган;

Фондның Административ Советы – Фондка идарә итүче иң югары коллегиаль орган;

Фондның Башкарма директоры – Фондның бердәнбер Башкарма органы;

ревизия комиссиясе – Фондның контроль-ревизия органы.

7.2. Фонд органнары вәкаләтләренең срогы 10 ел тәшкил итә. Әгәр Фонд органнарының вәкаләте срогы беткәннән соң Фондның яңа органнарын төзү турында карар кабул ителмәсә, аларның вәкаләтләре срогы алга таба һәр 10 ел саен үзеннән үзе озайтыла. Гамәлгә куючы карары нигезендә Фондның Попечительләр Советы һәм Фондның Административ Советы (яисә аларның әгъзалары) вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылырга мөмкин. Фондның Административ Советы карары белән Фондның Башкарма директоры вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылырга мөмкин.

## VIII. Фондның Попечительләр Советы

8.1. Фондның Попечительләр Советы Фондның эшчәнлегенә, Фондның башка органнары тарафыннан карарлар кабул ителүенә һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә, Фонд акчаларын файдалануга, Фондның законнар таләпләрен һәм әлеге Уставны үтәвенә күзәтчелек итә.

8.2. Фондның Попечительләр Советы үз эшчәнлеген җәмәгать башлангычларында башкара.

8.3. Фондның Попечительләр Советы персональ составы, аның Рәисе һәм Рәисе урынбасарлары Гамәлгә куючы тарафыннан раслана. Фондның

Попечительләр Советы Рәисенең һәм аның урынбасарларының вәкаләтләре срогы Фондның Попечительләр Советы вәкаләтләре срогына тәңгәл килә. Фондның Попечительләр Советы Рәисенең һәм аның урынбасарларының вәкаләтләре Гамәлгә куючы тарафыннан вакытыннан алда туктатылырга мөмкин.

8.4. Фондның Попечительләр Советы үзенең күзәтчелек функцияләрен башкару өчен түбәндәгеләргә хокуклы:

Фонд эшчәнлегенә кагылышлы барлык документлар аның өчен ачык булуын һәм Фондның финанс-хуҗалык эшчәнлегенә тикшерүләр уздыруны таләп итәргә;

әлеге Уставта каралган вәкаләтләр кысаларында Фондның Административ Советының, Башкарма директорының һәм ревизия комиссиясенең эшчәнлегенә күзәтчелек итәргә;

Фондның Административ Советы, Башкарма директоры һәм ревизия комиссиясе кабул итә торган карарларның Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килү-килмәвен тикшереп торырга;

Фондның Административ Советы, Башкарма директоры һәм ревизия комиссиясе кабул итә торган карарларның дөрес үтәлешенә күзәтчелек итәргә;

Фондның Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарын һәм Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләрен үтәү-үтәмәвен күзәтеп торырга;

Фондның мөлкәтен һәм башка акчаларын файдалануны тикшереп торуны башкарырга;

кирәк булганда, Фондның Административ Советын җыюны таләп итәргә һәм аның утырышы көн тәртибенә тәкъдимнәр кертергә.

8.5. Фондның Попечительләр Советы кирәк булган саен, әмма кимендә елга бер тапкыр җыела. Фондның Попечительләр Советы утырышлары аның Рәисе башлангычы белән чакырыла. Фондның Попечительләр Советын чакыру турындагы тәкъдимнәр шулай ук Фондның Административ Советы Җитәкчесе, Фондның Башкарма директоры тарафыннан бирелә ала.

8.6. Фондның Попечительләр Советы утырышы, анда аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, тулы хокуклы була.

Фондның Попечительләр Советы утырышларын аның Рәисе алып бара.

Фондның Попечительләр Советы Рәисе булмаганда, Фондның Попечительләр Советы утырышларын Фондның Попечительләр Советы Рәисе вәкаләт биргән аның урынбасарларының берсе алып бара.

8.7. Фондның Попечительләр Советы карарлары Фондның Попечительләр Советының утырышта катнашучы әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм Фондның Попечительләр Советы Рәисе тарафыннан имзалана.

8.8. Фондның Попечительләр Советы карары, аның утырышын уздырмыйча гына, читтән торып тавыш бирү юлы (сораштыру уздыру юлы) белән кабул ителергә мөмкин.

Читтән торып тавыш бирү турындагы хәбәрнамә тапшырыла торган һәм кабул ителә торган хәбәрләрнең чынбарлыкка туры килүен һәм аларның документ нигезендә раслануын тәэмин итүче почта, телеграф, телетайп, телефон, электрон һәм башка элемтә төрләре ярдәмендә тормышка ашырыла, яисә читтән торып тавыш бирү бюллетенендә (алга таба – бюллетень) күрсәтелгән бюллетень кабул ителә торган датага кимендә 10 көн кала Фондның Попечительләр Советы әгъзасына кул куйдырып шәхсән тапшырыла.

Хәбәрнамәгә мәҗбүри рәвештә көн тәртибенә куелган мәсьәләләр буенча барлык кирәкле документлар, шулай ук көн тәртибе һәм бюллетень теркәлә. Бюллетеньдә аның кайсы вакытка кадәр кабул ителәчәге датасы, ул җибәрелергә тиешле урын күрсәтелә, көн тәртибе, тавыш бирүгә куелган мәсьәләләр исемлеге, алар буенча карарлар проекты теркәлә.

Хәбәрнамәдә Фондның Попечительләр Советы әгъзаларының тавыш бирү башланганчы барлык кирәкле материаллар һәм мәгълүматлар белән танышуы тәртибе бирелергә тиеш, анда көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләр кертү турындагы тәкъдим бирү мөмкинлеге һәм Фондның Попечительләр Советының барлык әгъзаларына тавыш бирү башланганчы үзгәртелгән көн тәртибе турында хәбәр итү мәҗбүрилеге күздә тотылырга тиеш.

Фондның Попечительләр Советының читтән торып тавыш бирү юлы белән кабул ителгән карарлары:

Фондның Попечительләр Советының тавыш бирүдә катнашучы әгъзалары тавышының гади күпчелеге белән кабул ителә;

Фондның Попечительләр Советы әгъзаларына тавыш бирү йомгакларына хисап рәвешендә читтән торып тавыш бирү нәтиҗәләре турындагы беркетмә төзелгәннән соң биш календарь көннән дә соңга калмыйча читтән торып тавыш бирү өчен каралган тәртиптә тапшырыла.

## IX. Фондның Административ Советы

9.1. Фондның Административ Советы Фондка идарә итүче иң югары коллегиаль орган булып тора.

9.2. Фондның Административ Советы үз эшчәнлеген җәмәгать башлангычларында башкара.

9.3. Фондның Административ Советы персональ составы һәм аның Рәисе Гамәлгә куючы тарафыннан раслана. Фондның Административ Советы Рәисенең вәкаләтләре срогы Фондның Попечительләр Советы вәкаләтләре срогына тәңгәл килә. Фондның Попечительләр Советы Рәисенең вәкаләтләре Гамәлгә куючы тарафыннан вакытыннан алда туктатылырга мөмкин.

9.4. Фондның Административ Советының гадәттән тыш компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

Гамәлгә куючыга Фонд уставына үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

Фондның Башкарма директорын вазыйфага сайлау һәм вазыйфадан азат итү;

Фонд эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләрен билгеләү, аның мөлкәтен һәм Фонд акчаларын булдыру һәм файдалану принципларын билгеләү;

Фондның органнарын булдыру һәм аларның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату (әлеге Уставта каралган очраклардан тыш);

Фондның ревизия комиссиясе составын раслау, аның вәкаләтләрен һәм эшчәнлек тәртибен билгеләү;

Фондның аудиторлык оешмасын яисә хосусый аудиторын раслау;

Фондның Башкарма директоры тарафыннан бирелгән Фонд бюджетын, аның еллык хисабын һәм еллык бухгалтерлык (финанс) хисабын карап тикшерү һәм раслау;

Фондның Башкарма директоры тарафыннан бирелгән Фонд Дирекциясе штат расписаниесен карау һәм раслау;

Фонд тарафыннан башка юридик затлар төзү һәм (яисә) аларда Фондның катнашуы турындагы карарлар кабул итү;

Фонд филиалларын булдыру һәм вәкиллекләрен ачу, алар турындагы нигезләмәләрне раслау;

законнарда каралаган очракларда, Фонд тарафыннан башкарыла торган алыш-бирешләрне хуплау.

Фондның Административ Советының гадәттән тыш компетенциясенә кертелгән мәсьәләләре хәл итү өчен Фондның башка органнарына тапшырыла алмый.

9.5. Фондның Административ Советы кирәк булган саен, әмма кимендә елга ике тапкыр җыела. Фондның Административ Советы утырышлары аның Җитәкчесе башлангычы белән чакырыла. Фондның Административ Советын чакыру турындагы тәкъдимнәр шулай ук Фондның Попечительләр Советы Рәисе, Фондның Башкарма директоры тарафыннан бирелә ала.

9.6. Фондның Административ Советы утырышы, анда аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, тулы хокуклы була.

Фондның Административ Советы утырышларын аның Рәисе алып бара.

9.7. Фондның Административ Советы карарлары Фондның Административ Советының утырышта катнашучы әгъзаларының күпчелеге тавышы белән кабул ителә һәм Фондның Административ Советы Рәисе тарафыннан имзалана. Фондның Административ Советының гадәттән тыш компетенциясе мәсьәләләре буенча карарлар Фондның Административ Советының аның утырышында катнашучы әгъзалары тавышларының кимендә өчтән ике өлешен тәшкил иткән квалификацияле күпчелек тавыш белән кабул ителә.

9.8. Фондның Административ Советы карарлары, Фондның Административ Советының гадәттән тыш компетенциясе мәсьәләләренә кагылышлы карарлар кабул итүдән тыш, утырыш уздырмыйча гына, читтән торып тавыш бирү юлы (сораштыру уздыру юлы) белән кабул ителә ала.

Читтән торып тавыш бирү турындагы хәбәрнамә тапшырыла торган һәм кабул ителә торган хәбәрләрнең чынбарлыкка туры килүен һәм аларның документ нигезендә раслануын тәэмин итүче почта, телеграф, телетайп, телефон, электрон һәм башка элемтә төрләре ярдәмендә тормышка ашырыла, яисә читтән торып тавыш бирү бюллетенендә (алга таба – бюллетень) күрсәтелгән бюллетень кабул ителә торган датага кимендә 10 көн кала Фондның Административ Советы әгъзасына кул куйдырып шәхсән тапшырыла.

Хәбәрнамәгә мәҗбүри рәвештә көн тәртибенә куелган мәсьәләләр буенча барлык кирәкле документлар, шулай ук көн тәртибе һәм бюллетень теркәлә. Бюллетеньдә аның кайсы вакытка кадәр кабул ителәчәге датасы, ул җибәрелергә тиешле урын күрсәтелә, көн тәртибе, тавыш бирүгә куелган мәсьәләләр исемлеге, алар буенча карарлар проекты теркәлә.

Хәбәрнамәдә Фондның Административ Советы әгъзаларының тавыш бирү башланганчы барлык кирәкле материаллар һәм мәгълүматлар белән танышу тәртибе бирелергә тиеш, анда көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләр кертү турындагы тәкъдим бирү мөмкинлеге һәм Фондның Административ Советының барлык әгъзаларына тавыш бирү башланганчы үзгәртелгән көн тәртибе турында хәбәр итү мәҗбүрилеге күздә тотылырга тиеш.

Фондның Административ Советының читтән торып тавыш бирү юлы белән кабул ителгән карарлары:

тавыш бирүдә катнашучы әгъзаларның күпчелек тавышы белән кабул ителә;

Фондның Административ Советы әгъзаларына тавыш бирү йомгакларына хисап рәвешендә читтән торып тавыш бирү нәтиҗәләре турындагы беркетмә төзелгәннән соң 5 календарь көннән дә соңга калмыйча читтән торып тавыш бирү өчен каралган тәртиптә тапшырыла.

## X. Фондның Башкарма директоры

10.1. Фондның бердәнбер Башкарма органы булып Фондның Башкарма директоры тора.

10.2. Фондның Башкарма директоры вазыйфага Фондның Административ Советы тарафыннан сайлап куела һәм азат ителә.

10.3. Фондның Башкарма директоры белән хезмәт шартнамәсен Фондның Административ Советы Җитәкчесе имзалый.

10.4. Фондның Башкарма директоры Фондның эшчәнлегенә агымдагы җитәкчелекне гамәлгә ашыра һәм үзенең эшчәнлегендә Гамәлгә куючы, Фондның Попечительләр Советы һәм Фондның Административ Советы алдында хисап тота.

Фондның Башкарма директоры эшчәнлеге аның аппараты – составы Фондның штат расписаниесе нигезендә аның хезмәткәрләреннән торган Фонд дирекциясе тарафыннан тәэмин ителә.

10.5. Фондның Башкарма директоры:

Фонд исеменнән ышаныч кәгазеннән башка гына эш йөртә, дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм оешмаларда аның мәнфәгатьләре вәкиле була;

Фонд мөлкәтеннән аның максатлары һәм бурычлары, Фондның Административ Советы карарлары нигезендә катгый рәвештә тиешенчә файдалана;

Фонд исеменнән шартнамәләр, шул исәптән хезмәт шартнамәләре төзи, ышаныч кәгазьләре бирә;

Фондның Административ Советына Фонд дирекциясенең штат расписаниесен карау һәм раслау өчен тапшыра, законнар нигезендә хезмәткәрләрне эшкә кабул итә һәм аларны эштән азат итә, алар арасында хезмәт йөкләмәләрен бүлә;

Фонд дирекциясенең структур бүлекчәләрен төзи, аларның нигезләмәләрен раслый;

үз компетенцияләре чикләрендә боерыклар чыгара һәм Фонд дирекциясенең барлык хезмәткәрләре өчен үтәү мәҗбүри булган күрсәтмәләр бирә;

Фондның Попечительләр Советының, Фондның Административ Советының аларның компетенцияләре чигендә кабул ителгән карарлары үтәлешен тәэмин итә;

Фондның исәбен һәм хисабын алып баруны оештыра;

Фондның Попечительләр Советының һәм Фондның Административ Советының компетенциясенә кертелгән сораулардан тыш, Фонд эшчәнлеге белән бәйле башка мәсьәләләрне хәл итә.

10.6. Фондның Башкарма директоры Фондның Административ Советы тарафыннан билгеләнгән срокларда аңа карауга һәм раслауга кварталлык, еллык хисапларны, еллык бухгалтерлык (финанс) хисабын тапшыра, шулай ук Фондның Попечительләр Советына Фонд эшчәнлеге белән бәйле башка мәсьәләләр буенча мәгълүмат тапшыра.

## XI. Фондның ревизия комиссиясе

11.1. Фондның ревизия комиссиясе Фондның финанс-хуҗалык эшчәнлеген контрольдә тоту өчен төзелә. Фондның ревизия комиссиясе составы, аның компетенциясе һәм эшчәнлек тәртибе Фондның Административ Советы тарафыннан раслана.

## XII. Мәнфәгатьләр каршылыгы

12.1. Фондның Башкарма директоры, шулай ук Фондның Попечительләр Советы Рәисе һәм әгъзалары, Фондның Административ Советы Җитәкчесе һәм әгъзалары, әгәр бу затлар әлеге оешмалар һәм гражданнар белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торса, әлеге оешмаларда катнашучы, кредитор яисә әлеге гражданнар белән якын туганлык

мөнәсәбәтләрендә торса яисә әлеге гражданнарның кредиторлары булса, Фондның теге яисә бу гамәлләр кылуында, шул исәптән башка оешмалар һәм гражданнар белән алыш-бирешләр башкаруында кызыксынган затлар (алга таба – кызыксынган затлар) дип танылa. Шул ук вакытта әлеге оешмалар яисә гражданнар Фонд өчен товарлар (хезмәтләр) китерүче, Фонд җитештерә торган товарлардан (хезмәтләрдән) күпләп файдаланучы булып тора, Фонд тарафыннан тулысынча яисә өлешчә төзелгән мөлкәткә ия була яисә Фондның мөлкәтеннән файдаланудан, аның белән эш итүдән файда алуы мөмкин була.

12.2. Фонд тарафыннан теге яисә бу гамәлләр кылынуда кызыксынганлык кызыксынган затлар һәм Фонд арасында мәнфәгатьләр каршылыгы китереп чыгара.

12.3. Кызыксынган затлар Фонд мәнфәгатьләрен, иң беренче чиратта аның эшчәнлеге максатларына карата, сакларга тиеш һәм Фондның мөмкинлекләреннән файдаланмаска яисә әлеге Уставта каралган максатлардан тыш, башка максатларда файдаланылуына юл куймаска бурычлы.

«Фонд мөмкинлекләре» термины дигәндә, Фонд ия булган мөлкәт, мөлкәти һәм мөлкәти булмаган хокуклар, эшкуарлык өлкәсендәге мөмкинлекләр, Фонд эшчәнлеге һәм аның планнары турындагы аның өчен әһәмияте зур булган мәгълүмат күздә тотыла.

12.4. Әгәр кызыксынган зат Фонд якларның берсе буларак анда катнашкан яки катнашырга ният кылган алыш-бирештә кызыксынган булса, шулай ук әлеге затның һәм Фондның әлеге яисә булачак алыш-бирешкә кагылышлы мәнфәгатьләре башка төрле каршылыкка керсә:

ул үзендә кызыксыну барлыкка килүе хакында алыш-бирeш уздыру турындагы карар кабул ителү вакытына кадәр хәбәр итәргә бурычлы;

алыш-бирeш Фондның Административ Советы тарафыннан хупланырга тиеш.

12.5. Кызыксынган зат аның тарафыннан Фондка китерелгән зарар күләме өчен Фонд алдында җаваплы була. Әгәр зыян берничә кызыксынган зат тарафыннан салынса, аларның Фонд каршындагы җаваплылыгы берләштерелә.

## XIII. Фондны ликвидацияләү

13.1. Фондны ликвидацияләү турындагы карарны кызыксынган затлар гаризасы нигезендә бары суд кына кабул итә ала.

13.2. Фонд түбәндәге очракларда ликвидацияләнергә мөмкин:

әгәр Фондның мөлкәте аның максатларын гамәлгә ашыру өчен җитәрлек булмаса һәм кирәкле мөлкәт алу мөмкинлеге булмаса;

әгәр Фондның максатларына ирешү мөмкин булмаса, ә Фонд эшчәнлеге максатларында тиешле үзгәртүләрне башкарып булмаса;

Фондның үз эшчәнлегендә әлеге Уставта билгеләнгән максатларыннан читкә китүе очрагында;

федераль законда каралган башка очракларда.

13.3. Фонд ликвидацияләнгәндә, кредиторлар таләпләрен канәгатьләндерүдән соң калган мөлкәт Фонд нинди мәнфәгатьләрдә төзелгән булса, Фонд уставы буенча шул максатларда тотыла. Әгәр Фондның мөлкәтен файдалану әлеге Устав нигезендә мөмкин булмаса, ул Татарстан Республикасы кеременә әйләнә.

13.4. Фондны ликвидацияләгәндә, барлык документлар (идарә, финанс-хуҗалык, кадрлар белән бәйле һәм башкалар) дәүләт архивына саклауга тапшырыла.

Документларны тапшыру һәм тәртипкә салу Фонд хезмәткәрләре тарафыннан һәм аның акчасы хисабына башкарыла.

13.5. Фондны ликвидацияләү моның турындагы язу Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертелгәннән соң тәмамланган, ә Фонд ябылган дип санала.